Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының утыз сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

10 октябрь, 2024 ел № 122

Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге торак пунктлары территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җыеннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 62 номерлы (2021 елның 25 декабрендәге 37 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Кощаково авыл җирлеге Советы карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Иске Кощаково авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

- 2024 елның 21 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Болын, Кормушкин, Кояшлы урамы буенча теркәлгән кешеләрнең гражданнар җыенын «ТУЛПАР» кибете янындагы парковкада үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Кощаково авыл җирлеге Иске Кощаково авылы Болын, Кормушкин, Кояшлы урамарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә (Каяшлы ур.) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова